**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында Нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 7 мартындагы ПУ-207 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалткан нигезләмәләре исемлегенең 9 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 14 июлендәге ПУ-649 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 03 июнь
№ 376

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «03» июнендәге
376 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (алга таба – Департамент) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Департамент Татарстан Республикасының эчке сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан үзенең конституциячел вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Департамент үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

4. Департамент Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

5. Департамент турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

II. Департаментның төп бурычлары

6. Департаментның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенең сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, коммерциячел булмаган башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы эчке сәясәт мәсьәләләре буенча консультация һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген тәэмин итү;

этноконфессиональ һәм иҗтимагый-сәяси өлкәләрдә эчке сәясәтне гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасында иҗтимагый-сәяси вазгыятьне мониторинглау, анализлау һәм фаразлау, сәяси планлаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисенә тәкъдимнәр әзерләү;

яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан үзенең конституциячел вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын мәгълүмати, аналитика һәм оештыру ягыннан тәэмин итү;

мәгариф мәсьәләләре (югары белем бирүдән тыш) буенча Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген мәгълүмати, аналитика һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

## III. Департаментның төп функцияләре

7. Департаментның төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

социаль-сәяси вазгыять, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, конфессияләр эчендә барган һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы буенча мәгълүмати-аналитик материалларны әзерләү, гомумиләштерү һәм системалаштыру;

Татарстан Республикасында җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү, социологик тикшеренүләр уздыруны оештыру;

иҗтимагый үсеш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисенә мәгълүмат бирү;

Татарстан Республикасы Рәисенә Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе, шулай ук башка вазыйфаи затларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, коммерциячел булмаган оешмалар һәм граждан җәмгыятенең башка институтлары уздыра торган чараларда катнашуына бәйле тәкъдимнәр бирү;

Татарстан Республикасы Рәисенең сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый, дини һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар лидерлары, фән һәм иҗат интеллигенциясе, халыкның төп социаль төркемнәре вәкилләре белән очрашуларын әзерләүдә катнашу;

үз компетенцияләре чикләрендә, Татарстан Республикасының мәгълүмат өлкәсендәге сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда вәкаләтле органнар белән берлектә Департамент эшчәнлеге мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламалары өчен материаллар әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыклары теленә һәм мәдәниятенә дәүләт ярдәме күрсәтү, аларны саклап калу һәм үстерү республика программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

нинди расадан, милләттән булуына, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, социаль, расачыл,

милли, тел яисә дингә мөнәсәбәт билгеләре буенча хокукларны чикләүнең һәм дискриминацияләүнең барлык формаларын булдырмау чараларын гамәлгә ашыруда катнашу;

гражданнарның бердәмлеген, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, аларның телен һәм мәдәниятен саклап калу һәм үстерүгә, аз санлы халыкларның хокукларын яклауга, мигрантларның социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуына, милләтара (этносара) низагларны булдырмауга һәм милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итүгә юнәлтелгән башка чараларны гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча чараларны үтәүдә катнашу;

Татарстан Республикасында мәгарифне (югары белем бирүдән тыш) үстерү мәсьәләләре буенча чараларны гамәлгә ашыруда катнашу;

«Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм файдалану концепциясен һәм Татарстан Республикасында талантларга стратегик идарә буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләүдә катнашу;

Татарстан Республикасында креатив индустрияләр өлкәсен үстерүгә булышлык итү;

иҗтимагый әһәмияткә ия башлангычларга ярдәм итү, гражданнарның дәүләт программаларында һәм проектларында, аларның Татарстан Республикасын үстерүдә катнашу мөмкинлеген арттыру;

Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының социаль челтәрләрдәге рәсми аккаунтларын алып бару;

электрон демократия формаларын үстерүгә ярдәм итү;

Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисенең мәкаләләре, мөрәҗәгатьләре һәм чыгышлары тезисларын әзерләү;

Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары, беркетмәләре һәм йөкләмәләр исемлекләре проектларын әзерләүдә катнашу;

Департамент карамагындагы мәсьәләләр буенча закон актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлек итү;

үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары һәм йөкләмәләре үтәлешен тикшерүне оештыруда, аларны контрольдән алуның, башка чаралар күрүнең максатка ярашлылыгы турында бәяләмәләр әзерләү;

иҗтимагый-сәяси үсеш, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, конфессияләрдәге мөнәсәбәтләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, түгәрәк өстәлләр эшендә катнашу;

дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының дәүләтнең милли сәясәтен гамәлгә ашыру һәм конфессияләрдәге мөнәсәбәтләр, иҗтимагый-сәяси үсеш һәм граждан җәмгыяте институтларының функцияләве мәсьәләләренә күзәтчелек итүче хезмәткәрләрен әзерләүдә һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыруда катнашу;

Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләренең эш тәҗрибәсен гомумиләштерү, аларның эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү;

Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гомумроссия һәм төбәк иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, сәяси партияләр һәм аларның бүлекчәләре белән багланышларны һәм элемтәләрне үстерү.

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәләре буенча башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

## IV. Департаментның хокуклары

8. Үз функцияләрен тормышка ашыру өчен Департамент түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан тиешле мәгълүмат һәм материалларны соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фән һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә;

Департамент эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тикшеренүләр, конференцияләр, семинарлар, конкурслар, башка гавами акцияләр һәм чаралар оештырырга;

Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тематик мәгълүмати-белешмәлек һәм аналитик материаллар, күзәтүләр, шул исәптән электрон формада, чыгарырга;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайга салуга, Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси үсешенә зур өлеш керткән

гражданнарны бүләкләү һәм аларны дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү турындагы тәкъдимнәр бирергә;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча эшне камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр бирергә.

## V. Департаментның хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Департамент үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Департамент хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Департамент эшчәнлеген оештыру

11. Департаментның структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Департаментның структур бүлекчәләре түбәндәгеләр:

иҗтимагый-сәяси һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек бүлеге һәм иҗтимагый үсешне мониторинглау һәм фаразлау бүлеге кергән Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе;

дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге һәм мәгариф программалары һәм проектлары бүлеге кергән Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе;

Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе;

иҗтимагый проектлар бүлеге.

Департаментның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан раслана.

13. Департамент эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (алга таба –

Департамент җитәкчесе) җитәкчелек итә, ул Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

14. Департамент җитәкчесе:

Департамент эшен оештыра, Департаментка йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

Департаментның төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Департамент хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә һәм аларның вазыйфаи регламентларын һәм вазыйфаи инструкцияләрен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Департамент структурасы, штат саны, Департамент хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм вазыйфадан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Департамент хезмәткәрләрен бүләкләү яисә аларны дисциплинар җәзага тарту турында тәкъдимнәр бирә;

Департамент компетенциягә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән фикер алышуларда катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Департамент вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

15. Департамент җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын урынбасарларының берсе яисә Департаментның вәкаләтле башка вазыйфаи заты башкара.

16. Департамент җитәкчесе урынбасарлары һәм Департамент идарәләре башлыклары Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә. Департаментның башка хезмәткәрләре Департамент җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.